# КАРАР

**2022 елның 25 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 25 ноябрендә 2 этапта түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәр дүрт яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү; проект-смета документлары);
- Үрәсбаш авылы территориясен төзекләндерү.?

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 229 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 133.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 133 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәр дүрт яки аннан да күбрәк бала тәрбияләүче күп балалы гаиләләрдән; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын сүндерү машинасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
- урамны яктыртуны карап тоту (энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү; проект-смета документлары);
- Үрәсбаш авылы территориясен төзекләндерү;
- ял итү зонасы булдыру һәм төзекләндерү (проект - смета документлары, җир кишәрлеген рәсмиләштерү, хезмәт күрсәтүләр һәм эшләр өчен килешү буенча түләү);
- видеокүзәтү өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Үрәсбаш авылының сууткәргеч челтәрен һәм су башнясын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү (проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- спорт мәйданчыгына хезмәт күрсәтү?

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы В.Г. Сәфәров

ОГРН 1021607753133 ИНН 1623002015